Республика Татарстан
**ГЛАВА ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
423950, п.г.т.Уруссу ул.Пушкина, 38
тел.: (85593) 2-80-13
факс: (85593) 2-62-20

Татарстан Республикасы
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**
423950, Урыссу ш.т.б. Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-80-13
факс: (85593) 2-62-20

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**“**20**”** 03 2020 **г.** №23

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башлыгы карарына үзгәрешләр
кертү турында

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе Кодексы, Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы районы Советының 2015 елның 11 сентябрендәге 43 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы белән һәм Татарстан Республикасы Ютазы район Советының норматив-хокукый актларын тәртипкә салу максатларында, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башлыгының «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеге турында» 2019 елның 10 декабрендәге 84 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Преамбуладан һәм кушымтадан “Россия Федерациясенең административ хокук бозулар турында кодексы белән” сүзләрен алып ташларга.

1.2. 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Әлеге карарны «Ютазы таңы» («Ютазинская новь») газетасында рәсми бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый

мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.”

1.2. 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә”.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башлыгы урынбасары З. М. Әгълиева

Якупов Р. М.
(85593) 2-74-14